

Россия Президенты тарафыннан Ватанны саклаучылар елы дип игълан ителгән елда һәм Боек Ватан сугышында Жинvнен 80 еллыгын бәйрәм итv кысаларында Боек Ватан сугышында катнашучыларыбызга юбилей медальләре тапшыру дәвам ителә. Кочкурово районында ветераннарга «1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышында Жинvгә 80 ел» юбилей медален шулай ук тапшырып киләләр.

Әлеге районда бердән-бер генә булган татар авылында гомер итvче тыл хезмәтчәннәре, Хезмәт ветераннары Алия Хәсән кызы Казанбаеваны (рәсемдә) белән София Абдулла кызы Кафискинаны Мордовия Башлыгы һәм Мордовия Правительствосы Администрациясе Житәкчесенен беренче урынбасары Игорь Юрьевич Датков бvләкләп Боек Ватан сугышында халкыбызнын сындырылмавын, намус белән нык торуын, тыныч һәм чәчәк атучы киләчәккә юл салып, илне хәрабәләрдән кvтәрv очен кулдан килгәннен барысын да эшләвен билгеләп vткән. Сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре - яшь буын очен фидакарь, намуслы хезмәт vрнәге икәнен әйткән. Игорь Юрьевич хатын-кызларга сәламәтлек, иминлек һәм озын гомер теләгән.